**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы №115 «19» апреля 2024 ел.

Татарстан Республикасы Азнакай районы Урсай авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 ноябрендэге 99 номерлы номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында"гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында "гы 2023 елның 25 декабрендәге №628-ФЗ Федераль законы нигезендә

**Урсай** авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Урсай авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 ноябрендэге 99 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау хакында"гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә, 6 нчы статьяның 5 нче өлешен түбәндәге эчтәлектәге 12.1 пунктчасы белән тулыландырып, түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

«12.1) иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмати системасында «Электрон бюджет» капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат формалаштыра, аларга капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслау) чыганагы булып федераль бюджет акчалары тора (капиталь төзелеш объектларыннан һәм дәүләт оборона заказына кертелгән күчемсез милек объектларыннан тыш);».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай районы Урсай авыл җирлеге Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис З.Х.Рахимьянова